**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 15 апрель № 229

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 18 июнь, 420 нче карары белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси гомуми белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем алуны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси гомуми белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем алуны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 18 июнь, 420 нче карары белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси гомуми белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем алуны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр

буенча кредит бурычлары булмау.»;

2.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча кредит бурычлары булмауны раслый торган документ.»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлешләре субсидия бирү турыда килешүләрдә каралган очракларда хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидия алучы субсидияләрне кире кайтару вакытларын бозган очракта Министрлык субсидияләрне кире кайтару вакыты чыккан көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә законнарда билгеләнгән тәртиптә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарту буенча чаралар күрә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков